ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.08.2020 № 702

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елда Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны тәэмин итү турында» 2020 елның 11 февралендәге 123 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясы, 37 статьясы таләпләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 июнендәге 900 номерлы карары нигезендә нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елда Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны тәэмин итү турында» 2020 елның 11 февралендәге 123 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында түбәндәгеләрне билгеләргә:

- бер укучыга көненә бер тапкыр кайнар тукλануның уртача бәясе:
  7 яшьтән 11 яшькә кадәрге балаларга - 40 сум, 11 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларга - 43 сум;
- бер укучыга көненә ике тапкыр кайнар туклануның уртача бәясе:

7 яшьтән 11 яшькә кадәрге укучыга - 60 сум, 11 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларга - 63 сум.

11 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар өчен 7 сум 70 тиен күләмендә туклану бәясе җирле бюджет акчаларыннан түләнә, аерма әти-әниләр түләве хисабына».

1.2. 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

- «4. Тәэмин итәргә:
- 4.1. түбәндәге категориядәге укучыларны бер тапкыр түләүсез кайнар ризык белән тукландыруны:
- башлангыч гомуми белем алучы балаларны;
- 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдә тәрбияләнгән укучы балаларны;
- балигъ булмаган яшьтәге балаларны;
- гаиләдә бер кешегә туры килә торган уртача керем яшәү минимумыннан кимрәк булган балалы гаиләләрдәге балларны.

Гаиләнең җан башына уртача керем яшәү минимумы «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Мәгариф идарәсе» МКУ һәм «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ГКУ арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү нигезендә билгеләнә».

- фтизиатрда дәваланучы балаларны;
- дәүләт учреждениеләрендә тулысынча дәүләт тәэминатында булган балаларны;
- биш көнлек хәрби җыеннарда катнашучы 10 сыйныф үсмерләре.

4.2. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны ике тапкыр түләүсез кайнар ризык белән туклындыру.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусы медик-социаль экспертиза (МСЭ) белән билгеләнә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинга йөкләргә.

Җитәкче урынбасары Л.Ф. Нургаянов